| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 23 июнь г.Казань № 422

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2013 ел, 13 сентябрь, 656 нчы карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2013 ел, 13 сентябрь, 656 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 28 май, 361 нче, 2014 ел, 26 июнь, 440 нчы, 2015 ел, 11 май, 334 нче, 2015 ел, 11 ноябрь, 843 нче, 2016 ел, 17 май, 319 нчы, 2016 ел, 6 август, 535 нче, 2016 ел, 14 декабрь, 931 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау | Алдан бәяләү буенча, Программаны финанслауның гомуми күләме 3 619 639,03 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 305 637,53 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 3 314 001,5 мең сум: |

| күләмнәре | (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Ел | Җәлеп итү планлаштырылган федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Барлыгы |
| | 2014 | 45 872,03* | 455 283,4 | 501 155,43 |
| | 2015 | 48 807,5* | 491 749,6 | 540 557,1 |
| | 2016 | 34 321,0 | 494 718,3 | 529 039,3 |
| | 2017 | 41 516,0 | 479 100,0 | 520 616,0 |
| | 2018 | 43 301,0 | 493 413,0 | 536 714,0 |
| | 2019 | 45 076,0 | 449 868,6 | 494 944,6 |
| | 2020 | 46 744,0 | 449 868,6 | 496 612,6 |
| | Барысы | 305 637,53 | 3 314 001,5 | 3 619 639,03»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 3 619 639,03 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 305 637,53 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 3 314 001,5 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Җәлеп итү планлаштырылган федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 45 872,03* | 455 283,4 | 501 155,43 |
| 2015 | 48 807,5* | 491 749,6 | 540 557,1 |
| 2016 | 34 321,0 | 494 718,3 | 529 039,3 |
| 2017 | 41 516,0 | 479 100,0 | 520 616,0 |
| 2018 | 43 301,0 | 493 413,0 | 536 714,0 |
| 2019 | 45 076,0 | 449 868,6 | 494 944,6 |
| 2020 | 46 744,0 | 449 868,6 | 496 612,6 |
| Барысы | 305 637,53 | 3 314 001,5 | 3 619 639,03 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

Программага 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәләләр);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="11">«Еллар һәм чыга-наклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="4">Алдан бәяләү буенча, Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 056 583,53 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 305 637,53 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 750 946,0 мең сум:<br><br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Җәлеп итү планлаштырылган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td><td>Барлыгы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>45 872,03*</td><td>88 574,4</td><td>134 446,43</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>48 807,5*</td><td>113 105,9</td><td>161 913,4</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>34 321,0</td><td>120 181,9</td><td>154 502,9</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>41 516,0</td><td>103 159,1</td><td>144 675,1</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>43 301,0</td><td>106 500,5</td><td>149 801,5</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>45 076,0</td><td>109 712,1</td><td>154 788,1</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>46 744,0</td><td>109 712,1</td><td>156 456,1</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>305 637,53</td><td>750 946,0</td><td>1 056 583,53</td></tr>
<tr><td colspan="4">Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br>________________________<br>* 2014 һәм 2015 елларга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законнарында федераль бюджет акчасы өлешендә чыгымнар программа кодлары буенча чагылмаган.»;</td></tr>
</table>

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителеше

Алдан бәяләү буенча, Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 056 583,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 305 637,53 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 750 946,0 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Җәлеп итү планлаштырылган федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 45 872,03* | 88 574,4 | 134 446,43 |
| 2015 | 48 807,5* | 113 105,9 | 161 913,4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2016 | 34 321,0 | 120 181,9 | 154 502,9 |
| 2017 | 41 516,0 | 103 159,1 | 144 675,1 |
| 2018 | 43 301,0 | 106 500,5 | 149 801,5 |
| 2019 | 45 076,0 | 109 712,1 | 154 788,1 |
| 2020 | 46 744,0 | 109 712,1 | 156 456,1 |
| Барысы | 305 637,53 | 750 946,0 | 1 056 583,53 |

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

______________________

* 2014 һәм 2015 елларга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законнарында федераль бюджет акчасы өлешендә чыгымнар программа кодлары буенча чагылмаган.»;

Программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе институтын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның бурычлары | 1. Җәмәгать судьялары суд участокларын урнаштыру өчен шартларны яхшырту.<br>2. Җәмәгать судьялары суд участокларының техник ныгытылу, террорчылыкка каршы тору дәрәҗәсен күтәрү.<br>3. Җәмәгать судьялары суд участокларының мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрен үстерү.<br>4. Җәмәгать судьялары суд участокларының эшләвен тәэмин итү.<br>5. Җәмәгать судьялары суд участокларын матди-техник тәэмин итүне ныгыту.<br>6. Җәмәгать судьяларының һөнәри осталыгын күтәрү.»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Алдан бәяләү буенча, Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 563 055,5 мең сум тәшкил итә: |

| | | |
|---|---|---|
| | | (мең сум) |
| | Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
| | 2014 | 366 709,0 |
| | 2015 | 378 643,7 |
| | 2016 | 374 536,4 |
| | 2017 | 375 940,9 |
| | 2018 | 386 912,5 |
| | 2019 | 340 156,5 |
| | 2020 | 340 156,5 |
| | Барысы | 2 563 055,5 |
| | Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; | |

2 нче ярдәмче программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары һәм төп чаралар исемлеге, Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясен үстерү һәм ныгыту Ярдәмче программаның максаты булып тора.

Әлеге максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл иткәндә мөмкин була:

1. Җәмәгать судьялары суд участокларын урнаштыру өчен шартларны яхшырту.

2. Җәмәгать судьялары суд участокларының техник ныгытылу, террорчылыкка каршы тору дәрәҗәсен күтәрү.

3. Җәмәгать судьялары суд участокларының мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрен үстерү.

4. Җәмәгать судьялары суд участокларының эшләвен тәэмин итү.

5. Җәмәгать судьялары суд участокларын матди-техник тәэмин итүне ныгыту.

6. Җәмәгать судьяларының һөнәри осталыгын күтәрү.

Әлеге бурычлар кысаларында түбәндәге чараларны тормышка ашыру планлаштырыла:

җәмәгать судьялары суд участокларының биналарына һәм бүлмәләренә агымдагы ремонт;

җәмәгать судьялары суд участокларының биналарына һәм бүлмәләренә капиталь ремонт;

җәмәгать судьялары суд участокларын стационар металл табу җайланмалары белән тәэмин итү;

махсус программа белән тәэмин итүне кую һәм җайлау, аны техник тәэмин итү һәм кулланучыларны укыту;

җәмәгать судьялары аппаратын карап тоту;

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары суд участоклары өчен билгеләнгән нормалар буенча компьютер, оештыру техникасы һәм матди-техник чаралар сатып алу;

җәмәгать судьяларының квалификацияләрен күтәрү;

яңа билгеләнгән җәмәгать судьяларын яңадан әзерләү.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2020 еллар.

Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук чараларны финанслау күләмнәре аңарга кушымтада китерелә.»;

2 нче ярдәмче программаның III бүлеген редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

Ярдәмче программаны финанслау «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезләмәләренә нигезләнә, аның нигезендә җәмәгать судьялары эшчәнлеген финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан башкарыла.

Алдан бәяләү буенча, 2014 – 2020 елларда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 563 055,5 мең сум тәшкил итә.

Финанслау күләмнәренә, тиешле елга Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары түбәндәге таблицада китерелә:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|
| 2014 | 366 709,0 |
| 2015 | 378 643,7 |
| 2016 | 374 536,4 |
| 2017 | 375 940,9 |
| 2018 | 386 912,5 |
| 2019 | 340 156,5 |
| 2020 | 340 156,5 |
| Барысы | 2 563 055,5»; |

2 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\422.docx